# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# **КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 585-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 585-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2580-VI ДС

585-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2021 № 1 (I өлеш) «2026» саннарын «2031» саннарына алмаштырып үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 81 (I өлеш) «2026» саннарын «2031» саннарына алмаштырып үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

Закон проекты Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре бирү буенча вәкаләтләрен озайтуны күздә тота.

«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасының 31 муниципаль районының җирле үзидарә органнарына биш елга – 2020 елның 31 декабренә кадәр тиешле дәүләт вәкаләтләре бирелде. Татарстан Республикасының 2020 елның 26 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Законы белән җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре срогы 5 елга (2026 елның 1 гыйнварына кадәр) озайтылды.

Хәзерге вакытта дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре бирү вәкаләтләре республиканың түбәндәге муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына бирелгән:

| | | |
|---|---|---|
| Әгерҗе | Югары Ослан | Түбән Кама |
| Азнакай | Алабуга | Нурлат |
| Аксубай | Зәй | Балык Бистәсе |
| Алексеевск | Зеленодольск | Саба |
| Әлмәт | Кама Тамагы | Сарман |
| Апас | Кукмара | Спас |
| Арча | Лаеш | Тәтеш |
| Баулы | Лениногорск | Чистай |
| Балтач | Мамадыш | Ютазы |
| Бөгелмә | Менделеевск | |
| Буа | Минзәлә | |

Закон проекты җир законнары нормаларын куллану практикасын исәпкә алып эшләнгән, ул шәһәр җирлекләренең дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре бирү буенча вәкаләтләрен муниципаль районнар дәрәҗәсендә гамәлгә ашыруның иң оптималь варианты булуын күрсәтте.

Закон проекты белән муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләр срогын киләсе 5 елга (2031 елның 1 гыйнварына кадәр) озайту тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү муниципаль районнарга тапшырылган вәкаләтләрне финанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирүне таләп итәчәк.

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан алдан күрелгән ихтыяҗ 1185,0 мең сум, 1 244,5 мең сум, 1 306,7 мең сум тәшкил итә.